КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел,30 март г.Казань № 249

2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажир йөртүләрне планлаштыру документын раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә даими пассажир йөртүләрне планлаштыру документын әзерләү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 26 июль, 520 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими пассажир йөртүләрне планлаштыру документын әзерләү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажир йөртүләрне планлаштыру документын расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә даими пассажир йөртүләрне планлаштыру документын әзерләү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 26 июль, 520 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими пассажир

йөртүләрне планлаштыру документын әзерләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

4 нче пунктның тугызынчы абзацы үз көчен югалткан дип санарга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин